Казан (Идел буе) федераль университеты газетасы

# DARELFӨNYN
УНИВЕРСИТЕТ

№ 14 (27)

3 май 2012 ел

## • Ике авыз сүз

Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 27 апрель көнне чыккан боерыгы нигезендә Казан (Идел буе) федераль университетына Кама дәүләт инженерия-икътисад академиясе кушылды. Академиянең университет составына керүе инженерия өлкәсендә яңа үсеш юлына чыгарга ярдәм итәчәк.

• • • •

27 апрель көнне мәктәп укучыларының Республикакүләм «Гумилев укулары» фәнни-гамәли конференциясе узды. Конференция танылган галим Лев Гумилевның 100 еллык юбилеена багышланды. Фәнни чара кысаларында 3 секция эшләде. Татарстан Фәннәр академиясендә «түгәрәк өстәл» оештырылды. Укучылар педагоглар белән берлектә Алтын Урда, Болгар, Мәскәү дәүләтен өйрәнү тарихы, этногенез теориясенә бәйле проблемаларны күтәрде.

• • • •

Шул ук көнне Актлар залында Казан университеты Татар халык хорының 45 еллык һәм аның алыштыргысыз җитәкчесе, ТР атказанган сәнгать эшлеклесе Ирнис Рәхимуллинның 70 яшьлек юбилеена багышланган зур концерт узды. Әлеге коллектив Казан университетында татар халкының милли традицияләрен саклап калуга һәм студентларда музыка сәнгатенә мәхәббәт тәрбияләүдә зур өлеш кертә.

• • • •

Республикакүләм телевизион «Созвездие – Йолдызлык» яшьләр фестивале заманча эстрада сәнгатендә талантларны барлау өчен күп көч куя. Сайлап алу турларын уңышлы үтеп, КФУ ның Яр Чаллы филиалы филология һәм журналистика факультеты студенты Алинә Солтанова «Конферанс. Өлкән группа» номинациясендә җиңү яулады. Алинәне котлыйбыз һәм зур иҗади уңышлар телибез!

• • • •

Май бәйрәмнәре алдыннан КФУ ның Яр Чаллы филиалында КВН ның язгы кубогы өчен бәйге узды. Уен факультетара исем йөртсә дә, традиция буенча шәһәр командалары да катнашты. Безнең филиалны 4 команда тәкъдим итте. Берсеннән-берсе шаян командалар арасыннан җиңүчене билгеләү җиңел булмады. Төп бүләккә «Техназ» командасы лаек дип табылды.

• • • •

Апрельнең соңгы атнасында Татарстан Республикасында ел саен уздырыла торган Бөтенроссия «Мәрхәмәтлелекнең язгы атнасы» дигән акция үтте. Атна дәвамында узган марафонда актив катнашып, КФУ ның «Мәрхәмәтле кешеләр планетасы» дигән Ирекле үзәге командасы җиңү яулады. Һәр конкурста тапкырлыгы белән аерылып торган КФУ командасы балалар йортларында, социаль оешмаларда, уку йортында төрле акцияләр уздырды. «Ирекleләр»не җиңүләре белән тәбрикләп, алга таба да изге юлда булуларын телибез.

• • • •

11 май көнне «Хәзерге шартларда Россия һәм Польшада икътисадның банк һәм реаль секторлар бәйләнеше стратегиясе» дигән халыкара фәнни-гамәли конференция узачак. 4 секция утырышында фәнни карашлар, идеяләр, тикшеренүләрдән ясалган нәтиҗәләр белән танышу, тәҗрибә уртаклашу булачак, икътисадка бәйле докладлар тыңланачак.

• • • •

15 майда Бөтенроссия «Күпмилләтле дәүләттә никах һәм гаилә кору проблемалары: теоретик-эмпирик анализ» дигән исем астында фәнни-гамәли конференция узачак. Конференциядә кешелекнең киләчәге, Көнбатыш мөселманнарының көнкүреше, гаилә кора алмау кебек сорауларга җавап эзләнәчәк.

*kpfu.ru сайты материаллары файдаланылды.*



Алия Галимуллина фотосы

# «Мактаулы доктор»лар арта

**Динара ӘХМӘТОВА,**
хәбәрче

**Кичә, ягъни 2 май көнне Казан федераль университетында химия өлкәсендә Нобель премиясе лауреаты, РИКЕН президенты (Япониянең Нагоя шәһәре Физика-химия тикшерену институты), профессор Риоджи Нойори катнашында Гыйльми советның тантаналы утырышы узды.**

Риоджи Нойори 1938 елда Кобе шәһәрендә туа. Кечкенәдән үк химия фәне белән кызыксына башлый. Киото университетын тәмамлый, Гарвард университетында диссертация яклый. 1972 елда Нагойа университеты профессоры дәрәҗәсенә ирешә, бүгенге көндә дә бирედә эшли. 2001 елда химия өлкәсендә Нобель премиясен ала. Шулай ук 2006 елда оешкан мәгарифне үзгәртеп кору Советын җитәкли. 2005 елда RWTH университетының (Аахен, Германия) һәм Техник университетның (Мюнхен, Германия) дәрәҗәле докторы исемнәренә, 2010 елда М.В.Ломоносов исемендәге Россия Фәннәр академиясенең алтын медаленә лаек була. КФУ ның Гыйльми советы профессор Риоджи Нойорига 2011 елда «Казан университетының мактаулы докторы» исемен бирергә дигән карар кабул итә, ләкин Япониядәге җир тетрәү тантаналы чараны тоткарлый. КФУ ректоры Илшат Гафуров: «Сезнең кебек зур галим белән очрашу – безнең өчен зур дәрәҗә. Сезнең белән хезмәттәшлек итүнең роле алыштыргысыз», – диде һәм «Казан университетының мактаулы докторы» исемен тапшырды.

Физика-химия тикшеренүләр институты Япониянең эре фәнни үзәге булып тора. Аңа 1917 елда нигез салына. Япония буенча берничә уку йортын берләштергән институтта төрле өлкәләр: физика, химия, биология, медицина, техник һәм компьютер фәннәре буенча тикшеренү эшләре алып барыла. Шулай ук Бөекбритания, АКШ, Сингапур, Кытайда бүлекләре бар. РИКЕН белән Казан университеты арасындагы хезмәттәшлек тә соңгы ун елда үсешкә ирешә. Хезмәттәшлек итүгә беренче адымны КФУ профессоры Д.Таюрский ясый. Ул 2002 елда РИКЕН ның яңа гына ачылган Нанотехнологияләр үзәгенә бара. Шуннан соң хезмәттәшлек ныгый. 2008 елда уртак аспирантура ачыла. Нәтиҗәдә КФУ аспирантлары ике диплом алып чыга. Ике уку йорты арасындагы стратегик хезмәттәшлекнең концепциясе төзелә.

«Мин әлеге дәрәҗәле исем алуым белән бик бәхетле. Казан университетындагы хезмәттәшләрем минем өчен бик кадерле. Ректор Илшат Гафуровка зур рәхмәт сүзләремне җиткерәм. Сезнең уку йорты дөньякүләм билгеле галимнәр әзерләгән. Мин кечкенә чакта алар турында укып соклана идем. Безнең фән шул галимнәрдән башка бөтенләй булмас иде», – диде Япония галиме Риоджи Нойори.


Япония галимнәренең чираттагы визиты барышында КФУ һәм РИКЕН арасында фәнни хезмәттәшлек итү турындагы меморандумга кул куелды. Шулай ук Япониянең иң эре институты белән берлектә Физика институтында 3 лаборатория ачылды. Әлеге лабораторияләрдә башкарылган фәнни-тикшеренү эшләре зур адымнар белән алга баручы республика үсешендә мөһим урын алып торачак.

## • Фән дөньясында

# Яшьләргә - яшь җитәкче

**Наилә БАДЫКШАНОВА,**
матбугат үзәге хәбәрчесе

**27 апрель көнне КФУ да яшь галимнәрнең хисап-сайлау конференциясе булып узды. Чарада фәнни эшчәнлек буенча проректор Данис Нургалиев катнашты.**





Алия Галимуллина фотосы

Иң элек Данис Нургалиев яшь белгечләрне Казан федераль университетының формалашу этаплары, үсеше, яңа проектлары белән таныштырды. «Бу проектларны камилләштерү, яңаларын уйлап табу өчен, яшь галимнәрдән кызыклы фикерләр, эзләнүләр көтәбез. Яңа җиһазлар, барлык мөмкинлекләр дә булачак, бары тик сезнең идеяләр, яңа тәкъдимнәрегез, ә иң мөһиме, шушы дулкынга кереп китүегез кирәк! Университетыбызның киләчәге яшь буын кулында!» – дип, үзенең чыгышын төгәлләде ул.

**Ахыры 2нче биттә.**



Гыйльми совет, ректорат, Казан федераль университетының фәнни-педагогик җәмәгатьчелеге җитмеш җиденче яшендә якты дөньядан киткән күренекле җәмәгать эшлеклесе, Татарстанның халык язучысы, драматург, публицист, күпмилләтле республикабызның мәдәниятен баетуга зур өлеш керткән, Казан университеты студентлары, галимнәре белән һәрдаим иҗади бәйләнештә торган һәм мәгариф үсешенә бик зур өлеш керткән **Туфан Габдулла улы Миңнуллинның** туганнары һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

● Халыкара бәйләнешләр

# Без шундый якын

**Динара ӘХМӘТОВА,**
хәбәрче

26 апрель көнне Казан федераль университетына Казакъстанның Актүбә өлкәсеннән өлкә хакиме Архимед Мөхәмбәтов җитәкчелегендә делегация килде. Кунакларны ТР Премьер-министрының беренче урынбасары Равил Моратов озатып йөрде.

Визит кысаларында делегация КФУ ректоры Илшат Гафуров белән очрашты. Кунаклар өчен уку йортыбызның тарихы музее буенча бик мавыктыргыч экскурсия оештырылды. Кунаклар бик канәгать булып, хис-кичерешләре белән дә уртаклашты. «Актүбәнең хром кушылмалары заводы» акционерлык җәмгыяте идарәсе җитәкчесе Алексей Химич: «Безне бик яхшы каршы алдылар. Университет бөтен тарихны саклый икән. Бу сезнең традицияләрнең нык булуы турында сөйли. Шундый уку йорты булу Россиянең дә фән дәрәҗәсен югары күтәрә», – диде.

Очрашу барышында Казакъстан белән Татарстан республикалары арасында берничә меморандумга кул куелды. Ике як сатусәнәгать, мәдәният өлкәсе буенча, технопарклар белән хезмәттәшлек итү турында килеште. Казакъстан кунаклары бөек шагыйребез Г.Тукайның туган көненә багышланган тантаналы чараларда да катнашты, ТР Президенты Рөстәм Миннеханов белән очрашты.

Казакъстанның көнбатышында урнашкан Актүбә шәһәре Актүбә өлкәсенең административ үзәге булып тора. Әлеге өлкәдә татарлар бик актив яши. 1999 елда төзелгән «Шатлык» татар-башкорт оешмасы милләттәшләребезне берләштереп тора. Оешманы 13 елдан артык медицина өлкәсендә эшләгән Равил Корбангалиев җитәкли. Якшәмбе мәктәбендәге 3 сыйныфта 100 ләп укучы татар теле һәм әдәбияты серләренә өйрәнә. «Язгы моңнар» халык ансамбле моңлы җырларыбызны саклап калу, киләчәк буынга тапшыру өчен, бөтен көчен куя. Милли бәйрәмебез Сабан туен үткәрү дә күркәм традициягә әверелгән биредә. Анда безнең республика вәкилләре дә бик теләп катнаша. «Шунсы куандыра: өлкән буын белән яшьләр килешеп, дус-тату яши. Бик күп уртак проектларыбыз бар. Гомумән, татарлар гел ярдәмләшеп яшибез», – диде Равил әфәнде. «Мирас» татар яшьләре оешмасына һәрдаим 150 дән артык кеше йөри икән. Оешманың лидеры Наил Зәйнәгетдинов туган телебездә камил аралаша. «Татар иленнән бик ерак яшәсәк тә, гореф-гадәтләребезне, телебезне, йолаларны саклау – безнең төп бурыч», – диде ул.



Алия Галимуллина фотосы

Казан белән Актүбә шәһәрен 1000 км ераклык аерып тора. Ләкин без шундый якын. Уртак гореф-гадәтләребез бар, телебез, динебез охшаш. Милләттәшләребез ана телебезне саклап калу өчен тырыша. Кан-кардәшләребезнең бу визиты ике республика арасындагы дуслык күперен тагын бер кат ныгытты.

● Эшлекле сөйләшү

# Тәҗрибә уртаклашып

**Сиринә ТРОФИМОВА,**
хәбәрче

Узган атнада КФУ ның Н.Лобачевский исемендәге китапханә конференц-залында бер төркем университетыбыз галимнәре, укытучы һәм методистлары Сингапурның квалификация күтәрү өлкәсендә дөнья күләмендә үз рейтингын булдырган институт укытучылары Миссис Дас, Майк, Закия һәм башкаларның эш тәҗрибәләрен, тренингларын, лекцияләрен тыңлады.

8 сәгать буена барган бу чара 72 сәгатькә исәпләнгән курсның беренче көне булды. Курсның ахырында тыңлаучыларга халыкара дәрәҗәдәге сертификат бирелә.

Сингапур укытучылары эшчәнлегендә ул кадәр бездән аерылып торган нәрсәләр күп булмаса да, игътибарга лаеклары да җитәрлек. Мәсәлән, хәзерге көн мәктәп укучыларына, вуз студентларына дәрес, лекцияләрдә белем биргәндә, укытучының үз белемен, осталыгын бар тулылыгында файдалана белүе дөнья аренасында булган төрле ысулларга, формаларга җавап биреп бетерми. Без үзебезнең эшне күрсәтә белмибез. Аларның теле гади, аңлаешлы, ә без терминнар белән күбрәк мавыгабыз кебек тоела. Югыйсә, безнең Татарстан галимнәре, укытучылары да гыйлем, акыл буенча бер дә төшеп калганнардан түгел. Тик кечкенә генә Сингапур дәүләтенең белем бирү системасы буенча дөнья күләмендә беренчеләр рәтендә булуы, ә безнең бу өлкәдәге хәлебезне чагыштырсак, чынлап та, уйланырлык нәрсәләр байтак икәнлеге аңлашыла.



Алия Галимуллина фотосы

Курста катнашучыларга уңышлар телибез! Үзебезнекен югалтмыйча, яңалыкны өйрәнүнең зыяны тимәс, шәт.

● Фән дөньясында

# Яшьләргә - яшь җитәкче

**Башы 1нче биттә.**

1996 елдан бирле эшләп килгән яшь галимнәр ассоциациясе турында Наил Әбүбәкеров сөйләде. Бу берләшмәне ул үзе 2004 елдан бирле җитәкләгән. «Казан университетының иң яхшы яшь укытучысы», тренинглар, яшь мөгаллимнәр мәктәбе, тантаналы рәвештә аспирант булу, яшь галимнәрнең шәһәрара семинарларында катнашу – һәммәсе дә шушы берләшмә тарихына кереп калды.

Ә хәзер университет тормышындагы үзгәрешләр белән беррәттән, галимнәрнең дә үз оешмалары барлыкка килде. 27 апрель көнне 4 елга Яшь галимнәр ассоциациясенең яңа әгъзалары сайланды. Советка һәр факультеттан, институттан һәм филиаллардан берәр кеше билгеләнде.

Яшьләр бертавыштан үзләренең җитәкчеләре итеп Тарих институтының директор урынбасары, доцент Виктор Туманинны сайладылар. «Безнең эшчәнлекнең нәтиҗәсе югары булырга тиеш. Яшь галимнәребез алдында үзләреннән көтелгәннән дә уңышлырак итеп эшләү бурычы тора», – дип билгеләп үтте яңа җитәкче.

● Туган тел сагында

# Студентлар - төрле яшьтә

**Зилә ФӘСХИЕВА,**
хәбәрче

Рус телендә сөйләшүчеләргә татар теле курслары турында күпләрегезнең ишеткәне бардыр инде. Безгә, татар телен камил белүчеләргә бу берникадәр сәер дә тоелырга мөмкин: нигә инде аларга татар теле? Минем бу курслар турында ишетеп кенә каласым түгел, ә күрәсем үк килде. Шулай беркөнне татар филологиясе бүлегенең укытучысы Венера Акмал кызы Гариповадан мин дә татар теленә өйрәндем.

Атна ахыры булуга карамастан, «укучылар» Венера Акмаловнадан ярты сәгать алдан килеп утырганнар иде инде. Татар телен чамалы гына белгән бу «студентлар»ны күзәтәм: нәрсәдер кабатлыйлар, берберсе белән мәгълүмат алышалар. Өстәлләрендә бер буш урын да калдырмыйча, сүзлек, ниндидер китапчыклар, дәфтәрләр, тагын уку өчен кирәкле булган әсбапларны җәеп куйганнар. Эчтән генә уйлап утырам: көне буе укый торган без – студентларның сумкасыннан бөтен дәресләрнең дәфтәрләрен җыйсаң да, моның кадәр кәгазь чыкмый! Укытучы алар белән татар телендә исәнләшкәч, дәресне башлап җибәрделәр. Венера Акмаловна дәреснең һәр этабын төгәл итеп планлаштырган, күренеп тора! Сер итеп кенә әйтәм: дәрес башында алып кергән күрсәтмә материаллар арасында татар халык киеме кигән уртача зурлыктагы, матур гына курчак бар иде. Ул курчак белән нишләрләр икән дип, дәрес башыннан ук үзем дә кызыгып карап утырдым.

Татар телен өйрәнергә теләүче укучыларның яше төрлечә, шуңа карамастан бер дус группа булып формалашканнар. Диалоглар төзиләр, бер-берләренә сораулар бирәләр. Кайчакта укытучы сорый, алар җавап бирә алмый. Этеп тә җибәрәсең, төртәсең дә, юк инде, җавабын әйтә алмый. Уйлап утырам: берәү булса, я җикеренеп берәр сүз әйтер иде, яки шапылдап урындыкка барып утырыр иде. Ә Венера Акмаловнаның сабырлыгына исең китәрлек! Укучылары аны яраталар, кирәк чакта сорауларын бирергә дә оялмыйлар. Татар телен инде шактый үзләштергәннәр, «ипитозлыклары» бар. Май аенда укулар тәмам булачак, әмма укучыларның сүзләренә караганда, аларның әле бер дә таралышасылары килми.

Дәресләрне теләп өйрәнәләрме, дигән сорау урынсыз кебек. «Кайчакта шундый көннәр була: эштән соң кичке якта курсларга арып киләсең. Тиз генә укытып бетереп, өйгә кайтып ял итәсе килә. Тик мавыгып китеп, сәгатькә карарга да онытам. Берсендә шулай дәрес бетеп, шактый гына вакыт үткән, мин укучылар белән һаман сөйләшәм, дәрес аңлатам. Шунда ник берсе дәрес бетте инде, дип әйтсен! Студентлар белән ияләшкән бит: дәрес бетәргә ярты сәгать кала, инде алар сумкаларын җыя башлыйлар. Ә курсларда башкачарак атмосфера. Тырмашып, тел өйрәнергә теләүләрен күреп, үзем дә шаккатам һәм сокланам!» – дип, кичерешләре белән уртаклашты Венера Гарипова.

Дөрестән дә, ә нигә әле шундый мөмкинлек булганда файдаланмаска, ди?! Татарстан Республикасында татар телен белү беркемгә дә артык булмас иде...

***P.S. Ә теге татар халык киеменнән булган курчак ярдәмендә укучылар төсләрне өйрәнделәр. Кара чәчле, яшел калфаклы, кызыл иренле, алсу битле курчак иде ул...***

● Җиңүнең 67 еллыгына

# Германия җирләрендә урталай өзелмәсәк

**Мирфатыйх ЗӘКИЕВ**
КФУ профессоры,
хезмәт һәм сугыш ветераны

Үземнең биш яшьтәге чагым хәтергә нык уелып калган. 1933 елның ноябрь уртасы. Урман эченә урнашкан кечкенә бер авыл карга чумып утыра. Көн аяз, озакка сузылган бураннардан соң, бүген тыныч, аяз. Мине – биш яшьлек малайны – әни белән әби иртүк тиз генә киендерделәр дә иптәш малайларым булган бер күршегә кертеп куйдылар.

– Шушында гына уйна, урамга чыгып йөрмә, суык тидерерсең. Сине үзем кереп алырмын, – дип, әни күңелсезләнеп чыгып китте. Аның әчке дөньясының тынычсызлыгы миңа да бик нык тәэсир итте. Мин беренче мәртәбә көчле итеп, кайгылы итеп шунда еладым булса кирәк. Уенны да хуҗа апа уйнатырга тырышкач кына уйнагандай иттем. Ләкин әниемнең кайгылы чырае күз алдымнан һич китмәде.

Мине әни түгел, ә авылның бер агае күршеләрдән кереп алды һәм, җиргә бастырмыйча, күтәргән килеш үз өебезгә алып керде. Сәкедә ап-ак кәфенлеккә төрелгән эти чалкан яткырылган иде. Йөзе ачык. Аның янында елап, минем әнемне күтәреп, әни басып тора. Ул авырлы – өченче баласы булырга тиеш.

– Әй, балам, балам! Барыбыз да ятим калдык бит. Барыбыз да ачка үлмәсәк ярый инде! Гаиләдә эшче кеше калмады бит!

Җыелган авылдашлар әнине тынычландыра.

– Ул чаклы бетерешмә инде, Зәйнәптәй! Колхозның беренче председателе хатынын авыл халкы ярдәменнән ташламас!

Әни минем белән сөйләшүен дәвам итә:

– Әтиеңне карап, йөзен күңелеңә сеңдереп кал. Аның соңгы сүзе дә сезнең турыда булды.

– Мин китәм инде, бәхил бул. Минем малайлар кем булырлар икән, күз алдына зур кешеләр булыр дип китерәм! – диде ул җан биргәндә.

Әтиемнең гәүдәсен, чанага салып, зыяратка алып киттеләр. Без өйдә елашып калдык.

Әти үлеп, 5 ел үткәч, өч балалы әнигә Камил исемле бер ир йортка керде. Аның әтисен, кулак дип, гаиләсе белән Себергә сөргенгә җибәргән булганнар. 1938 елда аңа Себердән китәргә һәм туган җирләргә кайтырга насыйп булган. Үз авылына кермәгән, сөргенгә җибәрелүенә авыл халкы сәбәпче булган. Камил Әхмәт улы шулай итеп минем үги әтием булды, без аны үз әтиебез кебек ярата идек, акыллы, тыйнак иде ул.

1941 елда Ватан сугышы башланды, ике-өч көннән мин әни белән 18 чакрымдагы Ютазы станциясенә әтине сугышка озатырга киттем. Ютазы станциясенең читтәге рельсларына озын итеп өч рәт йөк вагоннары китереп тезгәннәр. Ютазының үзеннән, якын-тирә районнардан сугышка китәчәк яшь ирләрне шул вагоннарга тутырганнар; өченче рәттәге йөк вагоннарына сугышка алынган атларны төягәннәр. Үзләренең авылларда калган дусларын эзләпме, әллә сугышка кереп үләселәрен сизепме, алар кешниләр, пошкыралар, каты тавышлар чыгарып таптаналар.

Йөк вагоннарына төялгән якташларыма игътибар белән карап йөрим, әнинең боларның күбесе әйләнеп кайтмас, сугышта башын салып калыр инде, дигән сүзләре мине дә биләп алды, мин дә алар тирәсендә, күз яшьләрен тыя алмыйча, сытлыгып йөрим.

– Нигә сугышка китәсе бу абзыйлар шулай иске-москыларын кигәннәр? – дип әнигә сорау бирәм.



– Аларга тиздән солдат киеме кидерәчәкләр, бу иске-москыны чүплеккә ташлыйлар. Өйдәге яңарак киемнәрен уларына, энеләренә калдыралар, – дип җавап бирде әни.

Әтине күрше авылдан килгәннәр үз вагоннарына чакырып алдылар. Бу вагонга мине дә кертеп күрсәттеләр. Вагонның як-ягына салам-печән түшәлгән, өстән торбысы белән капланганнар. Уртада ашамлыклар өчен берничә әрҗә куелган, өстәл, имеш. Шунда безаз кызып та алганнар, берсе бик матур итеп тальянда уйный, башкалар аңа кушылып җырлый. Озатырга килүчеләр елый. Аларның гармунда уйнаулары һәм бер җырлары минем күңелемә уелып калды. Ул көйне мин әле дә тальянда оста гына башкарам. Җырының сүзләре менә ничек:

*Ал булырбыз, үлмәсәк,*
*Гөл булырбыз, үлмәсәк.*
*Германия җирләрендә*
*Урталай өзелмәсәк.*

Бу җырның соңгы ике юлы мине гомер буена озата барды. Әтием Камил Ржев шәһәре янында һәлак булды. Бу 1942 елның көзе иде. «Үлде», хәбәре килгәч, әни һәм өйдәге биш бала кычкырыпкычкырып еладык.

– Менә бит, улларым, кызларым, өйнең матчасына терәү куелган, терәү булмаса, түшәм дә ишелеп төшәр иде, нишләрбез, торырга өй булмаса, ашарга да узган елдан кырда калган черек, өшегән бәрәңгеләрне генә җыеп кыздырып ашыйбыз, киләчәктә анысы да булмаса, ни булыр!?

Мин, иң олы бала буларак, әнине юатырга тырышам, чөнки мин инде шактый олы егет, 13 яшь.

Бер ел сарык көткәннән соң, мин хәзер конюх булып эшлим. Сугышта яраланып кайткан бер слесарь-украин кешесеннән тимер эшләренә өйрәнәм.

Ржев дигән җирне ишеткән дә юк иде. Аны картадан эзләп таптым, Мәскәү янында гына икән! Менә бит фашистлар кайда ук кергәннәр, ә безнең абыйлар, әтиләр сугыш Германия җирендә генә булыр дип ышанып киттеләр.

13 яшемдә колхозның иң кирәкле кешесе – тимерчесе булдым, унынчыны тәмамлагач та колхоз тимерчелегендә эшли идем. Әни дә, энеләрем, сеңелләрем дә, тимерчегә бирелә торган азыктөлек булу сәбәпле, исән-имин калдылар. Күрше авылларда ачлыктан кешеләр күпләп үлделәр.

Тимерчелектә эшләп торганда, безнең мәктәп урнашкан Кәрәкәшле авылыннан сабакташларым килеп:

– Без Казанга укырга барабыз, син барсаң, әйдә безнең белән, – дип мине үгетли башладылар.

Хәрби училищегә җибәрәбез дип, мине төрле комиссияләрдән үткәргәннәр иде.

– Военкомат ни әйтер бит, – дип аптырабрак торганда, Гарәф Шәрәфетдинов:

– Университетка укырга керә алмасаң, хәрби училищегә китәрсең, керә алсаң, хәрби училищегә көчләп җибәрмәсләр, – диде.

Әни белән киңәшкәч, ул икенче көнне үк бер сарыкны суйдырды, яртысын пешереп, яртысын чи килеш бәләкәй арбага төяп, 18 чакрымдагы Ютазы базарына китте. Минем өчен юлга билетка акча кирәк иде.

Казанга мин физика буенча укырмын дип килгән идем. Шәһәрдә беренче төнне Фатих Махианов дигән, чыгышы буенча Кәрәкәшледән булган журналистларда кундык. Ул:

– Бер кая да йөрмисез. Казан университетында 1944 елда гына бик перспективалы бүлек ачылды. Ул – татар филологиясе, ягъни тел һәм әдәбияты бүлеге. Быел – 1946 ел, димәк, анда өченче мәртәбә кабул итү үткәрелә. Иртүк шунда керү имтиханнарын тапшырырга барасыз, – дип кырт кисте, бездән теләк сорап тормады.

1946 елда I курска кабул ителдек. Укый башладык, физикаматематика һәм химия фәннәре шаукымы минем баштан бик озак чыкмый йөрде.

Филологияне тирәнтен өйрәнә башлагач, күңел филологиягә тартылды, физик-математик логика булгангамы, бу фән миңа җиңел бирелде. Төрле физик эшләрдә йөреп укысам да, «5»ле билгеләре күбрәк керә иде.

Бу Ватан сугышыннан соңгы ачлык-хәерчелек еллары иде. Заводларда, фабрикаларда, тимер юл станцияләрендә авыр эшкә җигелеп, тамак туйдырырлык акча эшли алмасак, безнең күбебез студентлык елларын ахырына кадәр тарта алмаган булыр иде. Сугыш чорында әтисез калганнарга авылдан ярдәм көтеп ятарга туры килмәде. Шәхсән үзәмә килгәндә, мин аерымрак хәлдә идем: өйдән ярдәм алу түгел, киресенчә, үземнең колхоздагы тимерчелек һөнәренә таянып, дәрестән соң предприятиеләрдә хезмәт итеп, өйдә калган эне-сеңелләргә дә ярдәм итәргә тырыша идем.

Университетны кызыл дипломга тәмамлагач, мине аспирантурага алдылар, аны да мин вакытыннан алда диссертация яклап тәмамладым. Мине ул чагында Хатыйп Госман җитәкләгән татар теле һәм әдәбияты кафедрасына өлкән укытучы итеп эшкә калдырдылар. 1958 елда минем беренче зур күләмле «Хәзерге татар әдәби теле. Синтаксис» дигән



китабым дөнья күрде һәм конкурста университетның беренче бүләгенә лаек дип табылды. 1963 елның апрель аенда Казан университетында докторлык диссертациясе якладым, 1964 елда профессор дипломын алдым.

Җитәкче буларак та мине Казан университеты тәрбияләде. Студент елларында группаның комсомол җитәкчесе идем. Факультетта эшли башлагач, башта татар филологиясе бүлегенең парторгы итеп, соңрак тарих-филология факультетының партбюро секретаре итеп сайладылар. 1960 елда без Хатыйп Госман белән бергә ректор Михаил Нужин янына кереп, аны татар теле һәм әдәбияты кафедрасы базасында татар теле кафедрасы һәм татар әдәбияты кафедрасы төзергә кирәклегенә ышандырдык. Әдәбият кафедрасына мөдир итеп Х.Госман, тел кафедрасына мин сайландым. Кафедрага аспирантлар алу һәм тел буенча галимнәр әзерләү дә шул елда башланды. Менә шул рәвешле Казан университеты миңа галим һәм җитәкче буларак гомерлек юл салып бирде.

1965 елда университеттан Казан дәүләт педагогика институтына күчерелдем, башта анда фәнни эшләр буенча проректор, аннан 20 елга якын ректор булып эшләдем. Бу җаваплы хезмәтләремдә дә университет тәҗрибәсе ярдәм итте. Педагогика институтын күтәрүне без иң элек кафедраларны гыйльми кадрлар белән ныгытудан, студентларга уку һәм яшәү шартларын яхшыртудан башладык. Нәтиҗәдә 70 нче еллар уртасында Казан дәүләт педагогика институты (соңрак инде университет) – СССРдагы 250 педагогика институты арасында беренче урынга чыкты, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде.

Татарстанда гуманитар фәннәр академиясен төзерлек кеше кирәк дип, мине 1986 елда СССР фәннәр академиясе Казан филиалына караган Тел, әдәбият һәм тарих институтына директор итеп күчерделәр. Анда 17 ел эшләп Татарстан Фәннәр академиясен төзүдә актив катнашып, пенсиягә чыктым, ләкин фән һәм укыту өстендә эшләүне хәзер дә давам итәм.

Әйткәнемчә, үземнең татар теле өлкәсендәге фәнни оештыру эшемне университетта татар теле кафедрасы төзүдән, аңа җитәкчелек итүдән башладым. Педагогика институтында проректор һәм ректор булып эшләгәндә дә, үземә өстәмә эш итеп, татар тел белеме кафедрасын төзеп, анда җәмәгать тәртибендә мөдирлекне башкардым.

Мине күп мәртәбә Казан шәһәр советына, ике мәртәбә Татарстан Югары советына депутат итеп сайладылар. 1980-1990 елларда ТАССР ның Югары советы рәисе булып эшләдем. Рәислекне миннән соң Минтимер Шәрип улы дәвам итте.

Тел чыганакларын халык тарихын ачу эшендә файдалану барышында, минем тарафтан лингвистик археология дигән тарихи юнәлеш эшләнде. Шушы методны кулланып, барлык төркиләрнең этник тарихларын безнең эрага кадәр 6-5 меңенче елларга алып барып җиткердем. Хәзерге татарлар Чыңгызхан татарларыннан телне дә, антропологик типны да, гореф-гадәтләрне, яшәү культурасын да алмаган. Хәзерге татар халкының бу төп үзенчәлекләре моннан 7-5 мең еллар шушы территорияләрдә яшәгән җирле төрки кабиләләрдән килә.

Бу карашларны эченә алган тарихи китапларым берничә мәртәбә Мәскәүдә, казакълар башкаласы Астанада, Лондонда, Уфада, Татарстанда һәм ике мәртәбә Стамбулда басылып чыкты.

Хәзер мин – Татарстан фәннәр академиясенең Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында бүлек мөдире, Казан федераль университетының магистрлар белән шөгыльләнә торган лингвокультурология кафедрасында эшлим. 80 гә якын аспирантым, диссертацияләрен яклап, минем белән янәшә гыйльми эш алып баралар. 20 дән артык аспирантым доктор, профессор булды, академиклыкка сайланганнары да бар. Басылган хезмәтләрем 1000 гә якын. Монографияләр, дәреслекләр, кулланмалар булып чыккан китапларым 100 дән артык. Хәзер дә әле ике монографиям басылып ята, яңасын төзеп бетереп киләм. Сәламәтлегемне дә сакларга тырышам, көн саен иртән 45 минут йога күнекмәләре ясыйм, өч минут башымда торам. Бу һөнәргә мин ректор чагында, Пушкин урамында ике тулай торак бинасы салганда инфаркт алгач өйрәнергә мәҗбүр булдым. Хәзер 34 ел шушы күнекмәләрне һәр көн ясыйм.

Мине конференцияләрдә төркиләрнең этник тарихы буенча чыгыш ясарга, лекцияләр укырга Ашхабад, Астана, Уфа, Мәскәү, София, Урумчи кебек шәһәрләргә һаман чакыралар. Дөньяда танылган галимнәр белән тыгыз мөнәсәбәтләрне өзмәүне мин үземнең бәхетем дип саныйм.

**РАБОТА СТУДЕНТАМ и ДИПЛОМНИКАМ**

НПФ БЛАГОСОСТОЯНИЕ

В один из крупнейших Российских негосударственных пенсионных фондов НПФ «БЛАГОСОСТОЯНИЕ» (российские железные дороги) требуются сотрудники на должности финансового консультанта и руководителя группы.

- оформление по договору,
- гибкий график работы, возможность совмещения,
- оплата своевременная, обучение за счет компании,
- **оклад до 20 000** +премии(оклад по результатам собеседования),

Требования: аккуратность, активность, коммуникабельность, желание зарабатывать.
**Опыт работы не обязателен !!!**

**СТУДЕНТ - НЕ УПУСКАЙ ВОЗМОЖНОСТЬ - ЗАРАБОТАТЬ И ПОЛУЧИТЬ ПЕРВОНАЧАЛЬНЫЙ ОПЫТ РАБОТЫ В СВОБОДНОЕ ОТ УЧЕБЫ ВРЕМЯ!!!**

**Все подробности:**
**г.Казань, ул Московская, 31/6, офис 203**
**или по телефонам:**
**(843) 240-18-14, 259-18-89**
**http://www.vasheblagosostoyanie.ru/**

реклама

● Сәнгать

# Тәрбия һәм сәнгать берлеге

**Алисә БИЛАЛОВА,**
хәбәрче





Алия Галимуллина фотолары





«Милли хәзинә» Идел буе яшьләренең халык иҗаты конкурс-фестивале быел III тапкыр үткәрелде. Педагогик белем бирүче вузлар арасында башланып киткән әлеге фестиваль быел тагын да киңрәк үсеш алды.

Күргәнегезчә, конкурсның кысалары киңәйде. Сайлап алу турларында һәм гала-концертта чыгыш ясаучылар гадәттәгечә студентлар гына түгел, ә мәктәп балалары һәм махсус белем бирүче көллият укучылары да иде.

«Беренче елларында 15 катнашучы коллектив гариза бирсә, киләсендә инде аларның саны ике дистәдән артып китте. Быел исә әлеге сан тагын йөзгә артты», – дип белдерде жюри рәисе, педагогика фәннәре докторы Зилия Явгильдина.

Туган тел көне белән кайнаган Казан фестиваль кунакларын инде 25 апрель көнне каршы ала башлаган иде. Кемдер биредә янәдән үзенең иске дуслары белән очрашты, кемнәрдер исә үзләренең дуслык җепләрен киңәйтә торды.

26 апрель көнне үткән сайлап алу турлары да бик кызыклы иде. Филология һәм сәнгать институтының төп бинасы бу көнне үз милләтен, халкын сөюче студентлар авазы, елмаючан, шат йөзләр белән тулы иде. Катнашучыларның күплеге һәм елдан-ел остара баруы инде сайлап алу турларыннан ук күренә, сизелә.

Бар да матур, бар да көчле һәм кабатланмас. Тик, Гран-при иясе берәү генә булырга тиеш. Ул – М.Акмулла исемендәге Башкорт дәүләт педагогика университеты һәм аның бил бирмәс студентлары.

Әйе, жюри әгъзасы, ТР халык артисты Миңгол Галиев дөрес әйтә: акыллы кеше ул әле рухи яктан да бай, сәламәт булырга тиеш. «Менә шуны истә тотып, үзләренең студентларына белем биргәндә, рухи тәрбиянең дә ролен онытмаган уку йортларына без – жюри әгъзаларының игътибары һәм ихтирамы зур. «Милли хәзинә» конкурс-фестивалендә күпме яшьләребез, алай гына да түгел, күпме милләт, сәнгатьләр аралаша. Ил язмышына җаваплы кешеләрнең сәнгать белән тәрбияләнүе һәрберебезне сөендерә», – ди ул.

● Яз һәм хезмәт бәйрәме

# Ленин бабайның шат оныклары



**Нәзирә ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА,**
Филология һәм сәнгать институтының
белем бирү бүлеге җитәкчесе

Мин нигәдер бик еш йолдызчык таккан елтыр күзле малай-кызларны, бер йодрыкка бәйләгән, бер теләк, бер уй белән яшәткән пионер оешмасын, укучыларның чын дусты булган вожатыйларны, кызыл галстук бәйләгән пионерларны, дөрләп янган учакларны сагынып искә алам...

Без Ленин бабай оныклары идек. Әти-әни, дәү әти-әни, әби-бабай кебек үк якын, кадерле Ленин бабабыз бар иде безнең...

Үзен очратканыбыз булмаса да, һәр иртәдә сыйныф стенасындагы портретыннан матур елмаеп безгә карый ул. Портрет янәшәсендә зур, кызыл хәрефләр белән «Укырга, укырга һәм укырга!» дигән ялкынлы сүзләр эленеп тора. Уңга-сулга каранып, дәрестә тәртипсезләнеп утырсаң, өй эшен эшләп килмәсәң, бабайның кашлары җыерылыбрак, йөзе кырысланыбрак китә кебек. Һәрхәлдә безгә шулай тоела. Тәнәфес вакытларында да артык каты тәпәләшмәскә, тузынмаска тырышабыз. Ленин бабайны ачуландырсаң, октябрят булу турында уйлама да! Башкалар күкрәгенә бөдрә чәчле Володя сурәтләнгән йолдызчык тагып йөргәндә, син йөрерсең ала карга булып! Ә октябрят буласы бик килә!.. Дәрестән соң калып шигырьләр, җырлар кабатлыйбыз, октябрят булырга әзерләнәбез. Инде үзебезнең шигырьне генә түгел, бер-беребезнекен дә яттан өйрәнеп бетердек!

*«Без туганбыз октябрьда,*
*Без – октябрь баласы.*
*Октябрьда туганнарның*
*Лилин була бабасы!»* –

дип башлый көр тавышлы берәү. Укытучы апабыз: «Ленин, Ленин!» - дип төзәтмә кертә. Теге укучы тырышып-тырышып тагын «Лилин була бабасы!» дип кабатлый. Ул сөйләп бетерүгә:

«Куллар тотыштык,
Йолдыз-йолдызчык.
Һәммәбез тату –
Бездә чын дуслык.
Безнең йолдызчык
Каян төс алган?
Анда октябрь
Нурлары калган...» – дип, бар тавышка җыр сузабыз. Әйе, шигырьне дә, җырны да бар тавышка, бик тырышып башкарабыз. Ул да булмый: «Это Ленин дорогой, это Ленин наш родной», – дип русча да җырлап җибәрәбез әле.

Менә ул көн... Бу көнне без түземсезлек белән көттек. Ниһаять, бүген безнең ак алъяпкычларыбызда, костюмнарыбызда биш почмаклы кызыл йолдыз балкыячак. Сыйныф җитәкчебез башын селкеде, Камил абый баянын сузды, бәйрәм концерты башланды. Үзең сөйлисе шигырьне йөз кат кабатласаң да, монда онытыла икән! Аяк дер-дер калтырый, йөрәк дөп-дөп тибә, эч авырта башлады, җәмәгать! Ленин бабай портретына карап, аның елмаюын күргәч кенә бераз хәл кереп китте...

«Кем укуда иң оста,
Китап-дәфтәре чиста.
Ул бала – уңган бала,
«Октябрят» дип атала»,
– дип кычкырып сөйләдем мин. Шуннан барыбыз бергә: «Октябрятлар – булачак пионерлар. Октябрятлар – тату балалар, мәктәпне яраталар, өлкәннәрне хөрмәт итәләр», – дип тә кычкырдык.

Сөйләдек тә, җырладык та, биедек тә. Соңрак кызыл галстук таккан абый-апалар түшләребезгә йолдызчык кададылар, хәтта бүләк итеп китап та бирделәр әле. Шулай итеп октябрят тормышы башланып китте...

*(Дәвамы киләсе санда.)*









DARELFØNYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Баш мөхәррир - Илдар Азат улы Кәримов
Мөхәррир - Рамил Гомәр улы Ханнанов
Иҗат коллективы: С.М.Трофимова,
Д.Р.Әхмәтова, А.И.Билалова, З.Ф.Фәсхиева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч -
Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш.,
Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.

Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Карти» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Восстание ур., 60 й.